| | | |
|---|---|---|
| Республика Татарстан<br><br>СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br><br>САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | <br><br><br><br><br>e-mail: sab.sab@tatar.ru | Татарстан Республикасы<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br><br>САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«03» август 2018 ел № 22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан
2014 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән
44 нче номерлы «Татарстан Республикасы
Саба районы Саба шәһәр җирлегендә физик
затларның мөлкәт салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 32 нче бүлегенә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 64 нче маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Саба районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2014 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 44нче номерлы Саба шәһәр җирлеге Советы карары белән расланган "Саба шәһәр җирлегендә физик затларның мөлкәт салымы турында" карарына (Саба шәһәр җирлеге Советының 2015 елның 10 нчы августында кабул ителгән 39нчы номерлы, 2015 елның 7 октябрендә кабул ителгән 9нчы номерлы карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2 нче пункты 2 нче пунктчасы 2 нче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

"торак йортларны, торак йортларның өлешләрен";

1.2. карарның 2 нче пункты 3 нче пунктчасы 2 нче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

"фатирларны, фатирларның өлешләрен".

2. Әлеге карарның гамәлен 2015 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/saba адресы буенча һәм җирлекнең информацион стендларында бастырырга.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов